**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №126-21 2023 елның "18" апреленнән

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2018 елның 30 мартындагы 87-24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2019 елның 20 августындагы 143-35 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 155-38 номерлы, 2020 елның 22 октябрендәге 13-2 номерлы, 2021 елның 26 августындагы 47-10 номерлы, 2022 елның 12 октябрендәге 99-18 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 113-20 номерлы карар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Советы
**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2018 елның 30 мартындагы 87-24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәгә (2019 елның 20 августындагы 143-35 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 155-38 номерлы, 2020 елның 22 октябрендәге 13-2 номерлы, 2021 елның 26 августындагы 47-10 номерлы, 2022 елның 12 октябрендәге 99-18 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 113-20 номерлы карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегенең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Арендалана торган дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруда кече һәм урта эшкуарлык субъектларының катнашу үзенчәлекләре федераль закон белән билгеләнергә мөмкин. ".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru. бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин